**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 24 март № 183

г. Казань

Төзелеш-монтаж эшләре кыйммәтен
индексацияләү турында

Объектлар төзелеше кыйммәтен оптимальләштерү һәм тотрыклыландыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Төзелүче объектлар өчен 2015 елның 1 гыйнварыннан федераль бердәм бәяләр база дәрәҗәсенә карата (өстәмә кыйммәткә салымнан тыш) капиталь төзелеш объектларында төзелеш-монтаж эшләре кыйммәте үзгәрү индексларын (төзелеш төрләре, эшләр төрләре һәм тармаклар буенча) бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Капиталь төзелеш объектларының бу карар белән исәпкә алынмаган төзелеш төрләре, эшләр төрләре һәм тармаклары өчен төзүчеләр (техник заказчылар) тарафыннан төзелеш (реконструкция) кыйммәте – билгеләнгән тәртиптә эшләнгән һәм расланган индивидуаль индексларны кулланып яки төп төзелеш материалларына агымдагы бәяләрнең Татарстан Республикасы буенча бәяләр мониторингы нәтиҗәсендә билгеләнгән уртача дәрәҗәсен исәпкә алып, ресурс методы белән; ремонт эшләре кыйммәте, төп төзелеш материалларына агымдагы бәяләрнең Татарстан Республикасы буенча бәяләр мониторингы нәтиҗәсендә билгеләнгән уртача дәрәҗәсен исәпкә алып, ресурс методы белән куела дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеш-монтаж эшләре кыйммәтен индексацияләү турында» 2011 ел, 20 июль, 572 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\183.doc